КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2023 г. Казань № 284-П

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында урнашкан «Яңа Бикчәнтәй авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының чикләрен һәм файдалануның махсус режмын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә б о е р а м:

1. Расларга:

бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында урнашкан «Яңа Бикчәнтәй авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының чикләрен (бастырылып чыгарылырга тиеш түгел);

бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында урнашкан «Яңа Бикчәнтәй авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалануның махсус режимын.

2. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә күрсәтелгән ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне Бердәм күчемсез милек дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2023 елның 12 илнендәге 284-П боерыгына 2 кушымта

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районында урнашкан «Яңа Бикчәнтәй авылы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән **файдалануның махсус режимы**

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), 73-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану, шулай ук күрсәтелгән объектка гражданнарның керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның әлеге объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.

**1. Рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы тарафыннан бирелгән рөхсәт (ачык яфрак) нигезендә археологик предметларны эзләү һәм алу максаты булган эшләрне дә кертеп, һәйкәлне өйрәнү эшләрен башкару;

һәйкәлне саклау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелгән җир, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен башкару проектларында һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү турындагы мәҗбүри бүлекләр нигезендә саклау, һәйкәл территориясе чикләрендә урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану эшләре яисә һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү проектлары йә коткару археологик кыр эшләрен башкару планнары нигезендә саклау эшләрен башкару;

ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектының сакланышын тәэмин итү шарты белән, җир казу, төзелеш, мелиоратив, хуҗалык эшләрен, урманнардан файдалану һәм башка эшләр башкару;

һәйкәлне музейлаштыру чараларын үткәрү;

законнар нигезендә гражданнарның һәйкәлгә керүен оештыру;

кипкән үләннәрен чаптыру, үзлегеннән тишелгән һәм утыртылган агачларны һәм куакларны коры-сарыдан чистарту.

**2. Тыела:**

ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясендә туфрак катламын бозуга бәйле җир төзелеше, җир төзелеше, төзелеш, мелиоратив, урман төзекләндерү, хуҗалык һәм башка эшләрне проектлау һәм үткәрү, күрсәтелгән мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турындагы мәҗбүри бүлекләрне дәүләт хакимиятенең тиешле вәкаләтле органы тарафыннан килештерелгән, мондый эшләр башкару проектларында яисә күрсәтелгән мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итү проектларында йә башкарыла торган эшләрнең ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объектына йогынтысын бәяләүне үз эченә алган коткару археологик кыр эшләрен башкару планын гамәлгә ашырмыйча;

билгеләнгән урыннардан тыш чүп-чар, көнкүреш калдыклары чүплеге ясау.